# МИНЕМ АВЫЛЫМ – ИҢ-ИҢЕ…

**Туган өен белмәгән**
**Туган авылын белерме?**
**Туган авылын белмәгән**
**Туган илен белерме?**

Туган ил. Туган авыл. Туган як.

Һәркем өчен бу сүзләр бик якын һәм кадерле. Кеше өчен туган илдән дә кадерлерәк җир юк. Аны ярату гына җитми, ә тарихи үткәнен дә белергә кирәк.

**Хәтерләүдән курыкма син**

- Һәр нигезнең, һәр авылның
- Һәр каланың үткәне бар...
- Гыйбрәт алырлык мирасның
- Калганы бар, киткәне бар...

- Хәтерләүдән курыкма син!
- Үткәнеңне онытма син!

# КӨМЕШ КҮЛЕМ-ТУГАН АВЫЛЫМ




Көмеш Күлем, туып үскән җирем!
Яратам мин һәрбер почмагың.
Атамалар тарихыңны белеп
Үссә иде нәни дусларым.


Кемеш-Куль

Әй, авыл, син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда... Нинди тын вә нинди буш!



# Туган авылым Көмеш Күл.

Мидхәт Юнысов сүзләре. И.Дәүләтшин көе.

- Көмеш Күл- безнең авыл.
- Тими аңа җил-давыл.
- Горур таулар саклый аны:
- “Тыныч яшә,-дип,- авыл!”
- Их, Көмеш Күл, Көмеш Күл,
- Башкаларга үрнәк бул,
- Тормышны алып барганда,
- Безнең өчен терәк бул.
- Челтер-челтер иңеш ага,
- Урта ярып авылны,
- Чишмәсеннән сулар эчсәң,
- Яшәртәдер җаныңны.
- Их, Көмеш Күл, Көмеш Күл,
- Сина килә бик күп юл.
- Изге теләк белән килсән,
- Авылыбызда кунак бул.

# Авыл тарихы

- Көмеш Күл авылы узган гасырның 50 нче елларына кадәр Биләтле (хәзерге вакытта да бу төбәктә яшәүче өлкән яшьтәге кешеләр авылны шулай дип йөртәләр) исеме белән йөри. Биләтле атамасының килеп чыгышы борынгы болгар-татар телендәге “билән, батынкы җир, ияр кебек билләнеп эчкә кереп торган чокырлы урын” ны аңлаткан. Димәк, Көмеш Күл – билләре батып торган урыннары күп булган иярсыман җир, чокырлы җирдә урнашкан авыл. Авылыбызны урталай ярып, Өске елгасы агып үтә. Елга атамасы монголча ус “елга”, яки  ус (ан) “су”сүзләреннән алынган.

- Көмеш Күл авылының исеме бигрәк матур! Бай тарихлы авыл ул Көмеш Күл! Имеш, бик күп еллар элек хәзерге Чишмә урамында зур гына бер күл җәелеп яткан. Аның суы саф, көмештәй чиста булган. Язларын һәр елны бу күлгә пар аккошлар кайткан. Узган-киткән юлчылар өчен дә күл яхшы ял итү урыны булган. Аның даны еракларга таралган. Кешеләр бу тирәгә тартыла башлаганнар. Йортлар салып, төпләнеп калганнар. Халык күлгә карап сокланган, аның матурлыгын сакларга тырышкан. Күл үзенең суы белән һәркемне сөендергән, яшәеш чыганагы булып хезмәт иткән. Халык мондагы тормыш бары шушы күлгә бәйләнгән дип исәпләгән һәм авылга да Көмеш Күл дип исем биргән. Тора-бара күл саеккан һәм озакламый җир өстеннән бөтенләй юкка чыккан. Ә исеме авыл атамасында сакланып калган. Әле авыл турында мондый әкият тә бар.

- Имеш, борын-борын заманда булган ди бер күл. Аның суы көмештәй чиста, саф булган. Ул күлнең кырыенда камышлар шаулап үскән, төрле кошлар, җәнлекләр сөенешеп балалар үстергәннәр, күл тирәли чабышып уйнаганнар. Биредә күлнең бик якын дусты- Аккош та яшәгән. Аккош хәтта кышларын да җылы якларга китмәгән. Күл аны үзенең җылы куенында иркәләп йоклаткан, зәмһәрир суыклардан саклап калган. Аккош исә күл өстендә тирә-юньгә ямь биреп йөзгән, сузып-сузып дуслык җыры җырлаган.

- Шулай гөрләшеп яшәп ятканда, күл янына явыз аучы килеп чыккан. Ул үзенең шыксыз мылтыгы белән кошларны аулаган, җәнлекләрне үтергән, күлнең сөйгән дустына да ядрә тидергән. Күл, якын дускаен кочагына алып, ярасын юган, аны үлем тырнагыннан йолып калырга теләгән. Әмма Аккош дусты куенында соңгы сулышын алган һәм мәңгегә күзләрен йомган. И ярсыган күл, и ачуланган, дулкыннарын бер ярдан икенчесенә каккан. Аккош дускаен өзелеп-өзелеп сагынган. Көннән-көн сагышланып саргайган. Күл тирәсендә камышлар да үсми башлаган, кошлар да тынган. Әкренләп суы да кипкән. Күп тә үтми, ул тәмам юкка чыккан. Әнә шулай якын дусты хәсрәтеннән күлнең бары урыны гына калган. Озакламый бу тирәгә кешеләр килеп урнашкан, авыл барлыкка килгән. Күл һәм Аккошның тирән дуслыгын искә алып, авылны Көмеш Күл дип атаганнар. Авылның исеме әнә шулай барлыкка килгән , имеш.

# АВЫЛНЫҢ ИСКЕ ЗИРАТЫ






Кояш баешлары матур
Көмеш Күл буасында


СОКЛАНЫП ТУЙМАСЛЫК МАТУРЛЫК!

# Бөтен дөнья акка төренгән



# АВЫЛ МӘЧЕТЕ



# АВЫЛЫМ УРАМНАРЫ












# ЯЛПЫ УРАМЫ







# ЧИШМӘ УРАМЫ







# СУ БУЕ УРАМЫ





Берничә ел элек кенә бу урам гөрләп торган бит югыйсә








РИФАТ ЧИШМӘСЕ



Җир астыннан, кайнар мәхәббәттәй,
Салкын чишмә чыга ургылып.




МИНҺАҖ
ЧИШМӘСЕ


ГЫЙБИ ЧИШМӘСЕ



КӘШИФӘ ЧИШМӘСЕ


ЗИРАТ ЧИШМӘСЕ



# “КЫЗ ЙӨГЕРГӘН ЕЛГА”




“Манасыр тавы”







“Тула килесе”


КЕРӘЧ ТАВЫ

# “Керәч тавы”





# БЕЗНЕҢ МӘКТӘП



# Көмеш Күл мәктәбе тарихы

1860 елда Түбән Биләтле авылы мулласы хәзерге мәчет урынында мәдрәсә салдыра.
1895-1900 елларда Гайнетдин улы Сәләхетдин икенче мәдрәсә салдыра.
1918-1919 елларда мәктәптә Фәйзрахманов Габдрахман укыта.
1920-1922 башлангыч мәктәптә Гаянов Габдулла укыта
1923-1928 мәктәптә Хөсәен һәм Хәдичә Габитовлар эшли.
1928-1942 елларда мәктәп мөдире Бикбов Хан була.
1943 ел мәктәпнең мөдир вазифасын Халиков М. башкара.
1946 елдан мәктәптә Фәттахов Кави укыта.Ул лаеклы ялга чыккач, мөдир булып Насыйрова Зөләйха, Рәхимуллина Рашидә, Җамалыева Суфия апалар эшләде.
1983елда Көмеш Күл авылында урта мәктәп ачыла. Мәктәп директоры итеп Мөгътәсимов Әлфәт Каюм улы билгеләнә.
1985 елда мәктәптә директор булып Шакиров Фәнил Мәҗит улы эшли башлый.
1998-2006 елларда мәктәп белән Галимханов Таһир Әхмәдулла улы җитәкчелек итә.
2006 елдан Көмеш Күл гомуми белем мәктәбе директоры -Кашапова Дания Таһир кызы.

# УКЫТУЧЫМ, СИН БИТ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ БАЛАЧАКНЫҢ АЯЗ КҮГЕНДӘ



# БАЛАЛАР БАКЧАСЫ




Авылда балалар бакчасы
1980 нче елларда ачыла.
2006 нчы елда бакча
мәктәп бинасына
күчерелә.
Бүген анда 7 бала
тәрбияләнә.










МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ


СӘХНӘ ИМАН
ЯШӘҮ ЯМАН


СӘХНӘ-ВӘГЪДӘ, СӘХНӘ-ИМАН-
АННАН БАШКА ЯШӘҮ ЯМАН



# УКУЧЫЛАР СӘХНӘДӘ






АВЫЛЫБЫЗНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫ – “МИРАС” АНСАМБЛЕ

# БЕРКЕМ ДӘ, БЕРНӘРСӘ ДӘ ОНЫТЫЛМЫЙ

Көмеш Күлдән Бөек Ватан сугышына 155 кеше киткән,
102 се яу кырында мәңгелеккә ятып калган





# Авылым уңганнары

Бәйләү-чигү остасы Җиһаншина Рәйхана апа





# Күпме күз нурлары түгелгән!





НИЧЕК МАТУУУР!

# Дәүләтшина Рәзинә апаның хезмәт җимешләре








# Авылыбызның иң өлкән кешесе



**Зәкиева Закирә Шакирҗан кызы**

**1926 нчы елның 10 нчы апрелендә Иске Чәбия авылында туган. 1947 елда Көмеш Күлгә кияүгә чыккан. 5 бала тәрбияләп үстергән. Гомер буе колхозда баш хисапчы булып эшләгән**

# Авылыбыз кибете



# ӘЛЕ КАЙЧАН ГЫНА БУ БИНА ГӨРЛӘП ТОРГАН. БИРЕДӘ КОЛХОЗ ИДАРӘСЕ, АВЫЛ СОВЕТЫ, ПОЧТА, АТС УРНАШКАН БУЛГАН





*Бу урыннар элек төзек иде,*
*Бүген шыксыз бушлык,*
*ташландык...*

"Урын-җир исемнәре - халыкның үз илен шагыйранә бизәве ул. Аларда халыкның холкы, тарихы, һәвәскәрлеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре чагылыш тапкан".

К.Паустовский

